| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮЛБАТ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| 422077, Республика Татарстан, с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57 тел. (84362) 43-7-22 | 422077, Татарстан Республикасы, Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт тел. (84362) 43-7-22 |

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
03.08.2021 №36

Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатыннан, Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2019 елның 23 апрелендә 31 номерлы карарының 1.1 нче пункты үз көчен югалткан дип санарга.
3. Юлбат авыл башкарама комитетының "Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының 23.04.2019 елның № 31 карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2019 елның 20 ноябрендәге 50 нче номерлы карар үз көчен югалткан дип санау хакында.
4. Юлбат авыл башкарама комитетының "Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының 23.04.2019 елның № 31 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында "2019 елның 2 декабрендә 51 нче номерлы карар үз көчен югалткан дип санау хакында.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълумати стендларында урнаштырырга.

мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Юлбат авыл
җирлеге башлыгы Т.Р.Шәмсиев